ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1 (1); 2001, № 3; 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3, № 6 (I өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), № 11 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 37 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 2 пунктында «Җәмәгать судьясы вәкаләтләре чоры тәмамланырга» сүзләреннән соң «, җәмәгать судьясына җәмәгать судьясы вазыйфасында булуның иң чик яшенә җитәргә» сүзләрен өстәргә;

2) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7 статья. **Җәмәгать судьясының вәкаләтләр чоры**

1. Җәмәгать судьясы беренче тапкыр вазыйфага өч елга сайлана. Җәмәгать судьясы вазыйфасын биләгән зат, күрсәтелгән чор узгач, әлеге вазыйфага сайлану өчен үз кандидатурасын кабат тәкъдим итәргә хокуклы.
2. Җәмәгать судьясы, кабат вазыйфага сайланганда, тиешле вазыйфага вәкаләтләр чоры чикләнмичә сайлана. Җәмәгать судьясы вазыйфасында булуның иң чик яше – 70 яшь.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2021 елның 5 июленнән үз көченә керә.

2. Әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары үз вәкаләтләрен алар сайланып куелган чор тәмамланганчы саклап калалар.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 22 июнь
№ 43-ТРЗ